КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 май г.Казань № 320

Территорияләрендә кулланучылар фискаль документларны фискаль мәгълүматлар операторлары аша электрон формада салым органнарына мәҗбүри җибәрүне күздә тотмый торган режимда контроль-касса техникасыннан файдалана алган, элемтә челтәрләреннән ераклашкан Татарстан Республикасы торак пунктлары исемлеген раслау турында

«Кулда булган акча белән исәп-хисапларны һәм (яки) электрон түләү чараларыннан файдаланып исәп-хисапларны гамәлгә ашырганда контроль-касса техникасыннан файдалану турында» 2003 елның 22 маендагы 54-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 7 пункт, Россия Федерациясе Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының «Элемтә челтәреннән ераклашкан җирлекләрне билгеләү критерийләрен раслау турында» 2016 ел, 5 декабрь, 616 нчы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Территорияләрендә кулланучылар фискаль документларны фискаль мәгълүматлар операторлары аша электрон формада салым органнарына мәҗбүри җибәрүне күздә тотмый торган режимда контроль-касса техникасыннан файдалана алган, элемтә челтәрләреннән ераклашкан Татарстан Республикасы торак пунктлары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Мәгълүмат технологияләре, элемтә һәм мәгълүмат саклау идарәсенә әлеге карарга имза куелган көннән соң биш көн эчендә Исемлекне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми сайтында (www.prav.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\320.docx